**Гөлшат Дамир  кызы Борханова,**
**аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле Актанышның икенче урта гомуми белем бирү мәктәбенең  югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

# “Актаныш чишмәләре”

## (экологик кичә эшкәртмәсе)

Бу таулар да синеке!
Елгалар да, таллар да,
Кышкы буराннар да,
Җәйге алсу таңнар да.

Күргән, ишеткән, тойган
Һәммә нәрсә синеке!
Ә син үзең кемнеке?
Ә син туган җирнеке!

Туган якны яратырга өйрәтү, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү җиңел эш түгел. Үгет-нәсихәт биреп кенә нәтиҗәгә ирешүе кыен. Моңа ничек ирешергә соң? Бары табигатьнең матурлыгын, гүзәллеген аңлау, ярату аркылы. Табигать белән гармониядә яшәгәндә генә кеше сәламәт була ала.
Мин укучыларымны туган җиребезнең серле урманнарына, чишмә буйларына сәяхәткә алып китәм. Урманнарның сихри тынлыгын, чишмәләрнең илаһи челтерәвен тыңларга өйрәтәм. Шушы гүзәллеккә сокланып, шигырьләр иҗат иткән шагыйрьләребезне искә төшерәм. Илһам чыганагы – табигатьнең хис-тойгыларга тәэсир итүе, күңелне сафландыруы, баетуы турында сөйлим. Рухи байлык, күңел байлыгы, табигатькә сакчыл караш турында сөйләшүләр нәтиҗәсендә “Авылым чишмәләрдән башлана” дигән видеоязма, авыл табигатенә багышланган фотоальбом, туган як турында җырлардан, шигырьләрдән, укучылар иншаларын һәм каләм тибрәтүче балалар иҗатыннан “Тибрәлә шигъри бишек” дигән күргәзмәләр, төбәгебез шагыйрьләре Г.Афзал, Э.Шәрифуллина, Л.Шагыйрьҗан, Л.Гыйлем иҗатларына багышлап төзелгән презентацияләр барлыкка килде. Җыелган материаллардан, күргән тәэсиратлардан чыгып, туган авылыбыз, аның чишмәләре, канатсызга канат, моңсызга моң, илһам бирә торган кабатланмас гүзәл табигатебез турында “Актаныш чишмәләре” дип исемләнгән экологик кичә сценариесе яздык. Без аны сезгә дә тәкъдим итәбез.

Актаныш... Безнең якларның гүзәллеген әйтеп тә, сөйләп тә бетерерлек түгел. Авылыбызның бер ягыннан бормаланып-бормаланып тын гына Агыйдел, бер ягыннан җырларда җырланган Сөн елгасы агып ята. Калган ике ягында офыкларга тоташкан урманнар, иксез-чиксез басулар, әрәмәлекләр, адым саен могҗизага тиң күренешләр һәм бихисап күп чишмәләр... Хәтта авыл урамыннан да чишмәләр агып ята.

**Җыр.** “Актанышым урамы” Л.Гыйлем сүзләре

Алып баручы:

Бүгенге кичәдә без авылыбызның урман-тауларына, чишмәләренә сәяхәт ясарбыз. Туган табигатебезне саклау турында сөйләшербез. Безнең сәламәтлегебез дә бит ашаган ризыкның, эчкән суларның чисталыгына, һаваның сафлыгына бәйләнгән.

Бүгенге кичәдә яңгыраячак шигырьләр, җырлар ямьле Актанышка атап язылган. Аларның авторлары балачакта туган җиребезнең чирәм үскән яшел урамнарында яланаяк йөгереп йөргәннәр, елгаларын иңләп су кергәннәр, болын-тугайларында печән чапканнар. Агыйдел буеның куе таллыгында сандугачлар белән серләшкәннәр.

1нче укучы:

Агыйделдән күренеп тора
Актаныш басмалары.
Кызлар чәчен үреп салса,
Җилферди тасмалары.

2нче укучы:

Каян барсаң, шуннан туры
Актанышның юллары,
Хезмәтләрдә җиңү яулый
Туган якның уллары.

3нче укучы:

Газиз дә син, ямьле дә син,
Нурлы да син, туган җир.
Кайтып, атна-ун көн үтми –
Юкка чыга бөтен чир.

4нче укучы:

Авылымның күпме серен
Саклый агач, куагы.
Ташлап китеп кайтканнар да
Туган якның кунагы.

5нче укучы:

Туган җирнең җылы җиле,
Шифалы һәрбер көне.
Җаннарны яктыга дәшә
Хәтта караңгы төне!

Алып баручы: Без үз авылыбызның матур табигате белән хаклы рәвештә горурланабыз. Ләкин без табигатьнең үзгәрә, ярлылана баруына да күз йомып карый алмыйбыз.

6нчы укучы:

Еракларга чишмә агып киткән
Гасыр-гасыр гомер буенча.
Яраларына тинтәк тирес түккән

Аны-моны уйлап тормыйча.

<u>7нче укучы:</u>

Төрле чуп-чар җыеп бара-бара,
Килеп җитә чишмә елгага.
Һәр тармагы пычрак яра-яра,
Идеал дә шулай болгана.

<u>Алып баручы:</u> Г.Афзалның бу шигъри юллары белән чишмә, елга, урман, күл буйлары пычратучылар, чүпләүчеләр, туган ягыбыз табигатенә битараф булган кешеләр, үзегезне таныдыгызмы? Табигать белән янәшә булыгыз, дуслар! Аны хөрмәт итегез, рәнҗетмегез! Төз наратларыбызны, меңъяшәр имәннәребезне, яшел болыннарыбызны, балыклы күлләребезне, саф сулы чишмәләребезне, бетерүгә юл куймыйк. Гүзәллекне, матурлыкны күрә белик. Алар – безнең өчен табигый матурлык кына түгел, ә бәлки рухи истәлек булып та торалар.

<u>8нче укучы:</u>

Әй, ямьле дә Сөн буйлары,
Матур аның таулары.
Тау өстендә шаулап үскән
Каен, нарат урманнары.

<u>1нче укучы:</u>

Күңелле соң җырлый-җырлый
Кырларга барулары.
Сөйгән ярдай җанга якын
Сөн буе авыллары.

<u>2нче укучы:</u>

Егетләрең – булган егет,
Батыр синең ирләрең.
Кызларың кайнар йөрәкле,
Уңган да киленнәрең.

<u>3нче укучы:</u>

Көмеш чишмәләрдән мөлдерәмә
Сирпеп алдым бәхет чиләген.
Сөн буеның куе таллыгында
Сандугачның чиштем телләрен.
Гаҗәп матур серле урманнарда
Каеннарга шигырь сөйләдем,
Кошлар кунды кайнар учларыма.
Кәккүк озын гомер теләде.

<u>Алып баручы:</u> Табигать байлыклары арасыннан су аерым урынны алып тора. Әйтик, металлны пластмасса белән алыштырырга мөмкин. Галимнәр, хәтта ясалма кояш та ясап була, диләр. Ә менә суны һични алыштыра алмый. Су – тереклек чыганагы. Халык элек-электән су чыганакларын изгегә

санаган. Борын-борыннан, гадәттә, авылларны зур һәм кечкенә елга, яисә чишмә буйларына салганнар.

4нче укучы:

Моңнар эзләп йөргән чакта
Юлыктым мин чишмәгә.
Эзләгәнем тапканыма
Күңел тулды хисләргә.
Кулларым белән чистарттым
Ашыгып чишмә юлын,
Бар сагышы, моңы белән
Эчтем мин аның суын.

5нче укучы:

Тау буйларында саф чишмә,
Кайда бассаң – шул төштә
Бабайлар белеп утырган
Урманлы, сулы төшкә.

(**“Авылым чишмәләрдән башлана” дигән видеоязма кабызыла**)

...Сызылып аткан җәйге авыл таңын сәламләүче чишмәләр җыры кемнең генә күңел кылларын тибрәтми икән? Һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы, үз агышы, үз юлы бар. Безнең Актаныш тирә-якта үзенең чишмәләре белән дә дан тота. Исемлеләре, исемсезләре бар аларның. Чишмә диюгә без иңнәренә көянтә-чиләк асып судан кайтучы газиз әниләребезне, апа-сеңелләребезне күз алдына китерәбез. Чишмәләр – чисталык, сафлык билгесе ул.

6нчы укучы:

Туган илкәй...
Ни аһәңле, назлы исем!
Сизәм анда болыннарның татлы исен.
Ишетәм анда каеннарның серле шавын,
Тау астында салкын чишмә чылтыравын.

7нче укучы:

Чишмәләрнең моңнары бар
Җырларымның барсында.
Башкаемны иям бары
Эчәр суым каршында.
Җырлыйлар “Хәмит”, “Мәликә”,
“Җидегән”, “Изгеләре”,
Моңнары белән елата
Актаныш чишмәләре.

8нче укучы:

Һәркайсының үз холкы бар,
Һәрберсенең үз тәме,
Чишмәләр җырлап торганда
Җиремнең бетмәс яме.
Ага һаман, алар тынмый,
Ташларны урый-урый,

Иссәләр дә каршы җилләр
Чишмәләр алга ургый.

Алып баручы: Ә хәзер чишмәләребез янына сәяхәткә кузгалыйк, ни сөйли икән алар безгә? **Шигырь.** Л.Шагыйрьҗан. "Чишмә белән көрәшү".
(**Видеоязма кабызыла**)
Мин – **Хәмит** чишмәсе! Минем дөньяга чыгып ага башлавыма күп гасырлар үтте. Шулвакыт эчендә минем янымда кемнәр генә булмады! Типсә, тимер өзәрдәй пәһлеван егетләр, тал чыбыгыдай нечкә билле кызлар, туйда су юлы башлаучы яшь киленнәр, ирләрен яуда югалткан, балалары ятим калган кайгылы аналар, гомерләрен тигезлек белән үткәргән әби-бабайлар.
Кешеләрне соңгы юлга озатыр алдыннан да суны миннән алалар. Барчасы шатлык-кайгылары, эчке серләре белән уртаклаша. Һәркайсы минем янымнан җиңеләеп, яшәү өчен дәрт һәм көч алып китә.

Мин – **Мәликә** чишмәсе! Тау астыннан агып чыгып, сөзәк ярдан улак аша агып төшәм мин. Үткән-барган юлчылар мин көйләгән җырларны тыңламыйча, минем белән хозурланмыйча, миңа сокланмыйча китмиләр.

1нче укучы: Әйе, бу чишмәгә сокланмау мөмкин түгел. Аның җырлы-чыңлы саф һәм пакъ суын кем генә яратмый икән?! Кешеләр монда сусауларын басар өчен, тәннәренә сихәт алыр өчен, моң тыңлар өчен дә киләләр. Әйе, әйе, чишмә моңын. Чишмәнең челтер-челтер челтерәгән чыңы – аның кабатланмас, җаннарны биләүче моңы инде ул.

Мин – **Җидегән** чишмә! Мин авыл уртасыннан агам. Җәен печән чабарга йөрүче печәнчеләр, мал көтүчеләр, Агыйдел буенда җиләк җыючылар яхшы белә мине. Мин аларны ташларга бәрелеп-бәрелеп, чылтыр шат тавышым белән озата барам.
Минем суым саф, салкын, тәмле. Тик сез, кешеләр, минем яныма чүпләр ташламагыз, янымда үскән агачларны сындырмагыз. Шул чагында кыңгыраудай тавышым, җырлый-җырлый агуым еракларга ишетелер. Минем тавышыма иш булып, кошлар кушылырлар.

Мин – **Изгеләр** чишмәсе! Авылның төньягына карап агам. Шуңа күрә суым салкын, саф, татлы. Уйларыгыз, эш-гамәлләрегез изге булса гына, мин сезне шифалы, сәламәтлеккә файдалы суым белән сыйлармын. Яныма утырып ял итегез, суымны эчеп, арган тәннәрегезгә сихәт алыгыз. Шул вакытта "үз итәрсез, тәм табарсыз, ямь табарсыз җиремдә".

Алып баручы: Туган җир, туган авыл. Аның табигате кешегә һәрчак көч бирә, илһам бирә. Шуңа күрә күп язучыларның, шагыйрьләрнең, композиторларның, рәссамнарның иҗатында төп тема булып туган як тора.
2нче укучы:
Җир-Суыма җаным гашыйк –

Ырудан килә бары,
Туган туфрак изгелеге
Җибәрми мине ары.

Иркен болын-кырларым,
Борма-борма юлларым,
Җиләклек янында гына
Елмаялар елларым.

<u>3нче укучы:</u>
Басуларда иген шаулый,
Назлый, иркәли җиле,
Син минем җырлы бишегем,
Моңым син, Аккош иле.

<u>Алып баручы:</u> Туган авыл, туган җир. Кеше үзенең туган җиреннән никадәр газизрәк, кадерлерәк тоела. Чөнки кешенең тәнендәге күзәнәкләр туган җирдә үскән ризыктан көч алган. Авыл тирәсендәге урман шаулавыннан, челтерәп аккан чишмә, кошлар сайраган тавышлардан кешенең тойгылары, хисләре яңарган.
Читтә яшәгән чакта Кеше һәрчак күңеле белән туган җирен сагынып яши. Олыгая башлагач, балачакта эчкән чишмә суын эчәсе, туган як һавасын сулыйсы килә. Чөнки ул яшәгән җирдә бөтенләй башка су, башка һава. Шуңа күрә кеше олыгайган саен, туган җиренә ныграк тартыла.
"Эх, шул чишмәнең суын бер генә эчәргә иде, хәл кереп китәр иде", – ди. Авылда үзегезгә таныш булмаган олы яшьтәге кешеләрне очратсагыз, аптырамагыз. Алар авылны сагынып, аның чишмә суларын эчәсе килеп кайткан булырлар.

<u>5нче укучы:</u>
Киләм тагын кичләрдә
Моң тыңларга чишмәгә,
Бүләк итәм җырым сиңа
Бизәп аһәң-хисләргә.
Бер күрәсем килә авылымны,
Эчәр идем чишмә суларын.
Йөрәгемә дәртләр өстәр иде
Авылымның яшьлек моңнары.

**Җыр.** "Киләм тагын чишмәгә"
(Л.Гыйлем сүзләре, Р.Шәйдуллина музыкасы)

<u>6нчы укучы:</u> Шулай булгач, безгә барлык көчебез белән табигатьне сакларга кирәк түгелмени? Әйе, табигатьне сакларга кирәк. Моны әйтүе бик җиңел. Бу сорауны һәркем үзенә биреп карася, туган җиребез гөлбакчага әвереләчәк. Ә нигә соң елгаларыбыз һаман пычрана, кырларда чәчәкләр, сайрар кошлар

кими? Бу – җавапсызлыктан килә. Һәркем эшләгән эше өчен җаваплылык тоярга тиеш.

Алып баручы: Бөек Тукайның “Бала белән күбәләк” шигырен искә төшерик. Моннан йөз ел элек бала табигатькә чыгып, күбәләкнең хәлен сораша:
Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?
Ә без бу ыгы-зыгылы заманда, хәтта бер-беребезнең хәлен сорашырга да вакыт тапмыйбыз. Сорашыйк без хәлен табигатьнең! Хәлен белик тереклекнең! Шушы гүзәллеккә сокланып, кадерен белеп яшик! Үзебез өчен, киләчәк буыннар өчен саклыйк табигатьне, дуслар!

Файдаланылган әдәбият исемлеге:


1. “Агыйдел дулкыннары” җыентыгы, К., 1997.
2. Афзал Г. “Август йолдызлары”, К.,1995.
3. Гыйлем Л. “Актаныш чишмәләре”, Актаныш, 2004.
4. Моратов Ф., Хуҗин Й. “Актаныш –туган җирем”, “Идел-Пресс”, 2003.
5. Таңчулпан. “Кыргый чәчкә”, К., 2000.
6. Хәбибуллин И. “Сандугач керде күңелгә”, К., 1996.
7. Шагыйрьҗан Л. Шигырьләр, поэмалар. К., 1996.
8. Шәрифуллина Э. “Таң чыгы”, К., 1998.
9. Шәрифуллина Э. “Яңгыр җиле”, К., 1984.